ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

6 декабрь, 2024 ел № 39/9

Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең Һава кодексына һәм аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль закон», шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/10 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2022 елның 25 февралендәге 13/11, 2023 елның 29 июнендәге 25/8, 2023 елның 6 декабрендәге 28/8 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 70 пунктта «66 статьяның 12 өлеше» сүзләрен «66 статьяның 12 һәм 12.1 өлешләре» сүзләренә алыштырырга;

2) 83 пунктта «66 статьяның 12 өлеше» сүзләрен «66 статьяның 12 һәм 12.1 өлешләре» сүзләренә алыштырырга;

3) 86 пунктта түбәндәге эчтәлекле 3 һәм 4 пунктчалар өстәргә:

«3) 248-ФЗ номерлы законның 90 статьясы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында күрсәтмә бирү хакында карар;

«4) контроль төре турында Федераль законда, 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 3 өлеше нигезендә контроль төре турында Россия Федерациясе субъекты законында беркетелгән

карар, мондый мөмкинлек контроль төре турында Федераль законда, контроль төре турында Россия Федерациясе субъекты законында күрсәтелгән очракта».

2. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү чараларын башкаруга муниципаль контроль турында Ннгезләмәгә (Шәһәр Советының 2022 елның 25 февралендәге 13/11 номерлы, 2023 елның 29 июнендәге 25/8 Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 51 пунктта түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) контроль төре турында Федераль законда, 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 3 өлеше нигезендә контроль төре турында Россия Федерациясе субъекты законында беркетелгән карар, мондый мөмкинлек контроль төре турында Федераль законда, контроль төре турында Россия Федерациясе субъекты законында күрсәтелгән очракта».

2) 56 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«56. Урынга барып тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясы 2 өлеше 2 пунктында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел».

3. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/12 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Ннгезләмәгә (Шәһәр Советының 2022 елның 25 февралендәге 13/11, 2023 елның 29 июнендәге 25/8, 2023 елның 6 декабрендәге 28/8 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 68 пунктта «66 статьяның 12 өлеше» сүзләрен «66 статьяның 12 һәм 12.1 өлешләре» сүзләренә алыштырырга;

2) 82 пунктта «66 статьяның 12 өлеше» сүзләрен «66 статьяның 12 һәм 12.1 өлешләре» сүзләренә алыштырырга;

3) 87 пунктта «66 статьяның 12 өлеше» сүзләрен «66 статьяның 12 һәм 12.1 өлешләре» сүзләренә алыштырырга;

4) 90 пунктта түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) контроль төре турында Федераль законда, 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 3 өлеше нигезендә контроль төре турында Россия Федерациясе субъекты законында беркетелгән карар, мондый мөмкинлек контроль төре турында Федераль законда, контроль төре турында Россия Федерациясе субъекты законында күрсәтелгән очракта».

4. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/13 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Ннгезләмәгә (Шәһәр Советының 2022 елның 25 февралендәге 13/11, 2023 елның 29 июнендәге 25/8, 2023 елның 6 декабрендәге 28/8 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 59 пунктта «66 статьяның 12 өлеше» сүзләрен «66 статьяның 12 һәм 12.1 өлешләре» сүзләренә алыштырырга;

2) 61 пунктның 3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Урынга барып тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясы 2 өлеше 2 пунктында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел»;

3) 62 пунктта түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3) контроль төре турында Федераль законда, 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 3 өлеше нигезендә контроль төре турында Россия Федерациясе субъекты законында беркетелгән карар, мондый мөмкинлек контроль төре турында Федераль законда, контроль төре турында Россия Федерациясе субъекты законында күрсәтелгән очракта».

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев